КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1030

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1116 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субси-дияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен

раслау турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1116 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүче оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына әлеге гражданнар билгеләнешендәге продукцияне җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган (2022 елда – сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган) заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы;»;

6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавы. 2022 елда сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе 300 мең сумнан артмаска тиеш;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«сайлап алуда катнашучының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавы;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокта заявка бирә.

Сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат бирелгән, түбәндәге документлар теркәлгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада язылган заявка тапшыра:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка һәм сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган, билгеләнгән тәртиптә расланган өземтә (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль соратып ала);

суыткычлар һәм туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерү буенча фаразлана торган күләмнәр турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе. 2022 елда заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата оешмаларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында салым органының белешмә кәгазе тапшырыла. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан белешмә кәгазе тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль соратып ала;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан сайлап алуда катнашучының дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы заты яки баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын раслый торган өземтә;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча хисап чорына сайлап алуда катнашучының мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе, Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда салым декларациясе телекоммуникация элемтә каналлары буенча җибәрелүен һәм салым органы тарафыннан алынуын раслый торган квитанция һәм хәбәрнамә;

бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча хисап чорына оешмалар мөлкәтенә салым түләнгән, суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерү өчен файдаланыла торган сайлап алуда катнашучының мөлкәт объектлары турында мәгълүмат;

хисап чорына оешмалар мөлкәтенә салым түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

Федераль салым хезмәтенең «Салым органы тарафыннан исәпләнгән транспорт салымы һәм җир салымы суммалары турында хәбәр хатлары формаларын раслау турында, шулай ук Федераль салым хезмәтенең 2015 елның 15 апрелендәге ММВ-7-2/149@ номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 5 июлендәге ММВ-7-21/337@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча хисап чорына салым органы тарафыннан исәпләнгән җир салымы суммасы турында хәбәр хаты (алга таба – хәбәр хаты), сайлап алуда катнашучының телекоммуникация элемтә каналлары буенча хәбәр хатын алуын раслый торган квитанция;

бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча сайлап алуда катнашучы милкендә булган, суыткычлар, туңдыргычлар, медицина суыткыч җиһазы җитештерүне гамәлгә ашырганда җәлеп ителгән, хисап чорына җир салымы түләнгән җир кишәрлекләре турында мәгълүмат;

хисап чорына җир салымын түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (башка юридик затны сайлап алуда катнашучы юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

2022 елда сайлап алуда катнашучының Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз

тəэмин итүчелəр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавын раслый торган, йлап алуда катнашучының җитəкчесе һəм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмə кəгазе бирелə.

Заявка тегелгəн, номерланган, вəкалəтле зат тарафыннан кул куелган һəм аңа мөһер (булганда) сугылган булырга тиеш.

Министрлыкка тапшырыла торган мəгълүматларның дөрес булмавы, шулай ук сайлап алуда катнашучының документлары ялганлап ясалуы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендə җавап бирə.»;

16 пунктның өченче абзацын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«Килешүдə түбəндəгелəр карала: субсидия күлəме; субсидия бирү нəтиҗəсенең мəгънəлəре; субсидия бирелə торган чыгымнар юнəлешлəре; субсидияне күчерү тəртибе; субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тəртибенең һəм шартларының үтəлешен тикшерүгə (шул исəптəн субсидия бирү нəтиҗəлəренə ирешү өлешендə) һəм дəүлəт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һəм $269^2$ статьялары нигезендə тикшерүне гамəлгə ашыруга ризалыгы; субсидия бирелгəндə билгелəнгəн тəртип һəм шартлар бозылганда субсидияне кире кайтару очраклары; субсидия алучы тарафыннан бу Тəртип нигезендə субсидия бирү нəтиҗəлəре мəгънəлəренə ирешү турында хисап бирү тəртибе һəм сроклары, субсидия алучы тарафыннан өстəмə хисаплылык бирү сроклары һəм формалары (кирəк булганда); бу Тəртипнең 2 пунктында күрсəтелгəн, элек җиткерелгəн бюджет йөклəмəлəре лимитлары Министрлыкка киметелгəн очракта, субсидияне килешүдə билгелəнгəн күлəмдə бирү мөмкин булмавына китерə торган килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгə ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын килештерү).»;

18 пунктка түбəндəге эчтəлекле абзац өстəргə:

«2022 елда субсидия бирү нəтиҗəлəре күрсəткечлəренə килешүдə билгелəгəн срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерə торган шартлар барлыкка килгəн очракта, Министрлык, субсидия алучы белəн килештереп, субсидия күлəмен үзгəртмичə, субсидия бирү нəтиҗəлəренə ирешү срокларын (əмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендə килешүгə үзгəрешлəр кертү турында карар кабул итəргə хокуклы. Субсидия күлəмен үзгəртмичə, субсидия бирү нəтиҗəсенə ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нəтиҗəсе күрсəткечен киметү турында карар кабул итəргə хокуклы.»;

20 пунктны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«20. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тəртибе һəм шартлары үтəлешен (шул исəптəн субсидия бирү нəтиҗəсенə ирешү өлешендə) тикшерə. Дəүлəт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һəм $269^2$ статьялары нигезендə тикшерү үткəрə.

Субсидия бирү нəтиҗəлəренə ирешүне мониторинглау Министрлык тарафыннан, килешүдə билгелəнгəн субсидия бирү нəтиҗəлəре күрсəткечлəренə ирешүдəн һəм субсидия бирү нəтиҗəсен алу буенча тиешле чараны төгəллəү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгелəнгəн тəртиптə һəм формалар буенча үткəрелə.»;

24 пунктны түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«24. Субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту (мониторинглау) һәм аларны бозган өчен җаваплылык Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унтугызынчы һәм утыз тугызынчы абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин